ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 11 маенда
кабул ителде

## 1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас объектларын (алга таба – матди булмаган мәдәни мирас объектлары) ачыклау, саклап калу, өйрәнү, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2. Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) матди булмаган мәдәни мирас – этник, социаль яисә конфессиональ төркемгә хас булган, җәмгыятьнең мәдәни һәм милли үзенчәлегендә чагыла торган һәм, тарихи барлыкка килгән сюжетларда, образларда, аларны гәүдәләндерү стилистикасында гамәлгә ашырыла торган, телне, үз-үзеңне тоту, инану нормаларын һәм кагыйдәләрен, йолаларны, гореф-гадәтләрне, бәйрәмнәрне, фольклорны, халык декоратив-гамәли сәнгать предметлары, музыка кораллары, көнкүреш әйберләре әзерләү технологияләрен һәм халык сәнгать кануннарын кертеп, Татарстан Республикасында мәдәни төрлелекне ихтирам итәргә ярдәм итүче яшәү рәвешен, традицияләрне һәм аларны белдерү рәвешләрен үз эченә алган рухи, интеллектуаль һәм әхлакый-этик кыйммәтләр җыелмасы;

2) Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас объектлары реестры (алга таба – Реестр) – матди булмаган мәдәни мирас объектлары турында белешмәләрне үз эченә алган мәгълүмат системасы, күрсәтелгән объектларны дәүләт тарафыннан исәпкә алу максатларында аларның бердәйлеге һәм чагыштыра алырлык мөмкин булуы Реестр булдыруның гомуми принциплары, аны алып бару ысуллары һәм рәвешләре хисабына тәэмин ителә.

2 статья. **Матди булмаган мәдәни мирас объектлары төрләре**

1. Матди булмаган мәдәни мирас объектлары төрләре түбәндәгеләр:

1) халык белеме, инанулар, гореф-гадәтләр, традицияләр, фольклор әсәрләре, билгеле бер территориядә даими булдырыла торган йола яисә бәйрәм;

2) башкару сәнгатенең, шул исәптән сүз, вокаль, инструменталь, бию сәнгатенең уникаль рәвешләре;

3) халык декоратив-гамәли сәнгать предметлары, музыка кораллары, көнкүреш әйберләре әзерләү технологияләре;

4) тарихи барлыкка килгән сюжетларда, образларда һәм аларны гәүдәләндерү стилистикасында гамәлгә ашырыла торган конкрет территориядәге халык сәнгать кануннары.

2. Матди булмаган мәдәни мирас объектлары төрләренә, әлеге статьяның 1 өлешендә санап кителгәннәрдән тыш, матди булмаган мәдәни мирас объектларының аларны Реестрга кертү өчен матди булмаган мәдәни мирас объектлары туры килергә тиеш булган, әлеге Законның 6 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән критерийларга җавап бирә торган башка төрләре дә кертелергә мөмкин.

3 статья. **Матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклау, саклап калу, өйрәнү, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы әлеге Закон нигезендә Татарстан Республикасының хәзерге һәм киләчәк буыннары мәнфәгатьләрендә матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклауга, саклап калуга, өйрәнүгә, алардан файдалануга һәм аларны популярлаштыруга юнәлдерелгән сәясәт алып бара.

2. Матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклау, саклап калу, өйрәнү, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклау, саклап калу, өйрәнү, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклау, саклап калу, өйрәнү, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру өлкәсендәге Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм башкаруны тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

3) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3. Матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклау, саклап калу, өйрәнү, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклау, саклап калу, өйрәнү, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру өлкәсендә норматив хокукый актлар нәшер итү;

2) Татарстан Республикасы дәүләт программаларын төзегәндә һәм раслаганда матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклау, саклап калу, өйрәнү, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау мәсьәләләрен исәпкә алу;

3) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм әлеге Законда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендәге вәкаләтле органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Реестр алып бару;

2) матди булмаган мәдәни мирас объектларын саклап калу, өйрәнү, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы чараларын күрү;

3) матди булмаган мәдәни мирас объектлары торышын мониторинглау һәм тикшереп тору;

4) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм әлеге Законда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

### 4 статья. **Матди булмаган мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы**

1. Матди булмаган мәдәни мирас объектлары аларның юкка чыгуын, алар теркәлгән матди чыганакларның зарарлануын яисә бозылуын булдырмау максатларында, шулай ук аларны тискәре йогынтылардан яклау максатларында дәүләт саклавында булырга тиеш.

2. Матди булмаган мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) матди булмаган мәдәни мирас объектларының торышын мониторинглауны һәм тикшереп торуны;

2) матди булмаган мәдәни мирас объекты буларак кыйммәткә ия объектларны Реестр булдыру һәм алып бару юлы белән дәүләт исәбенә алуны;

3) әлеге Законның 1 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты нигезендә матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектларны (алга таба – матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектлар) ачыклауга, аларның көнкүрештә куллану рәвешләрен карауга һәм торышын бәяләүгә юнәлдерелгән фәнни тикшеренүләр оештыруны;

4) матди булмаган мәдәни мирас өлкәсендә дәүләт экспертизасы үткәрүне.

### 5 статья. **Реестр**

1. Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас объекты буларак кыйммәткә ия объектларны дәүләт исәбенә алу, аларны саклап калу, өйрәнү һәм популярлаштыру максатларында Реестр төзелә һәм алып барыла. Реестр турында нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

2. Реестрдагы белешмәләр башка мәгълүмат системаларын яисә әлеге мәгълүматтан файдалана торган (исәпкә ала торган) белешмәләр банкын булдырганда һәм алып барганда матди булмаган мәдәни мирас объектлары, мәдәни булмаган мирас объектларын көнкүрештә куллану һәм саклау алымнары

(рәвешләре), шулай ук күрсәтелгән объектларга бәйле матди предметларны саклау урыннары турында мәгълүматның төп чыганаклары булып тора.

3. Реестрдагы белешмәләр ачык, гомуми файдалана алырлык була һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

4. Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектларны Реестрга кертү турында карар Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан кабул ителә.

5. Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектны Реестрга кертү турында гариза Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органына матди булмаган мәдәни мирасны саклау һәм популярлаштыру белән кызыксынган зат тарафыннан бирелергә мөмкин. Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектны Реестрга кертү яисә кертүдән баш тарту турында карар гариза Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органында теркәлгән көннән алып иң күбе бер ел эчендә кабул ителә.

6. Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектны Реестрга кертү турындагы гаризада күрсәтелгән объектның исеме, матди булмаган мәдәни мирас объекты буларак аңа характеристика, шулай ук Реестрга кертү зарурлыгын нигезләү күрсәтелгән булырга тиеш.

7. Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектларга карата матди булмаган мәдәни мирас объектын Реестрга кертүне (кертүдән баш тартуны) нигезләү максатында дәүләт экспертизасы үткәрелә.

8. Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектларга дәүләт экспертизасы үткәрү тәртибе, экспертлар буларак җәлеп ителергә мөмкин булган физик һәм юридик затларны билгеләүгә таләпләр, әлеге экспертиза кысаларында тикшеренүләр үткәрү тәртибе, шулай ук дәүләт экспертизасына түләү күләмен билгеләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

9. Күрсәтелгән объектның әлеге Законның 6 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән критерийларга туры килмәве турында дәүләт экспертизасы бәяләмәсе матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектны Реестрга кертүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан карар кабул итү өчен нигез булып тора.

10. Гражданнар Реестрдагы белешмәләр чикләрендә матди булмаган мәдәни мирас объектлары турында мәгълүматны тоткарлыксыз алу хокукына ия.

6 статья. **Матди булмаган мәдәни мирас объектларын Реестрга кертү өчен сайлап алу критерийлары**

1. Матди булмаган мәдәни мирас объектлары аларны Реестрга кертү өчен түбәндәге критерийларга туры килергә тиеш:

1) тарихи һәм мәдәни әһәмиятлелеге;

2) этник, социаль яисә конфессиональ төркемнең мәдәни традициядә яисә мәдәният тарихында ныклап урнашу дәрәҗәсе;

3) мәдәни традициянең уникаль дәлиле буларак кыйммәте;

4) юкка чыгу куркынычы.

2. Матди булмаган мәдәни мирас объекты, әлеге статьяның 1 өлешендә билгеләнгән барлык критерийларга җавап бирсә, Реестрга кертелергә мөмкин.

## 7 статья. Матди булмаган мәдәни мирас объектларын саклап калу, өйрәнү, популярлаштыру һәм алардан файдалану

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы матди булмаган мәдәни мирас объектларын саклап калу, өйрәнү, популярлаштыру һәм алардан файдалану эшчәнлеген тәэмин итә һәм җайга сала.

2. Матди булмаган мәдәни мирас объектларын саклап калу матди булмаган мәдәни мирас объектларының оригинал рәвештә яшәешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә ала.

3. Матди булмаган мәдәни мирас объектларын өйрәнү фәнни, техник һәм сәнгати тикшеренүләр оештыру, матди булмаган мәдәни мирас объектларын нәтиҗәле саклау максатыннан фәнни-тикшеренү методологияләрен эшләү ярдәмендә, шулай ук федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында тыелмаган башка алымнар белән гамәлгә ашырыла.

4. Матди булмаган мәдәни мирас объектларын популярлаштыру һәм алардан файдалану җәмәгать чаралары үткәреп, шул исәптән мәдәни алмашу буенча, шулай ук мирас өлешләрен аларның ияләреннән яшь буынга тапшыру өчен шартлар тудыру һәм фәнни, фәнни-популяр һәм уку-укыту эшләрен нәшер итү юлы белән тәэмин ителә.

5. Физик һәм юридик затлар Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклауда, саклап калуда, популярлаштыруда һәм алардан файдалануда ярдәм күрсәтергә хокуклы.

## 8 статья. Матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклау, саклап калу, өйрәнү, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы чараларын финанслау

Матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклау, саклап калу, өйрәнү популярлаштыру һәм дәүләт саклавы чараларын финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән, шулай ук федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында тыелмаган башка чыганаклардан гамәлгә ашырыла.

9 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 26 май
№ 34-ТРЗ